


*Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 7, март, 2025 ел*



## Әниләр бәйрәме

8 Март - дөньяның күп кенә илләрендә хатын-кызларның казанышларын билгеләү көн. Бу көн беренче тапкыр 1909 елда Америкада, Социалистик хатын-кызларның өченче көнендә, үткәрелгән. Шуннан соң, 1910 елда Копенhagenда узган Халыкара Социалистик Хатын-кызлар Конгрессы вакытында 8 Март халыкара бәйрәм итеп игълан ителгән.

8 Мартта без хатын-кызларга, аларның җәмгыятьтә алып барган роленә, хезмәтләренә зур игътибар һәм хөрмәт белән карыйбыз. Хатын-кызлар — тормышның барлык өлкәләрендә актив катнашалар: алар гаилә коручы, хезмәткәр, җитәкче, укытучы, врач, һәм башкалар. Аларның тырышлыгы һәм хезмәте безнең тормышыбызны баета, ямьләндерә.

Бу көн хатын-кызларның ышанычлы һәм көчле шәхесләр итеп формалашуына да багышлана. Хатын-кызларның хокуклары, тигезлеге һәм мөмкинлекләре — җәмгыятьнең уңышлы һәм гармонияле үсешенең нигезе.

Татарстанда 8 Март традицион рәвештә бәйрәм ителә. Бу көнне үз әниләренә, апаларына, хатыннарына һәм җәмәгатьчелектә тырышкан башка хатын-кызларга чәчәкләр, бүләкләр һәм игътибар күрсәтелә.

Халыкара хатын-кызлар көне — бары тик бәйрәм генә түгел, ә шул ук вакытта хатын-кызларның хокуклары өчен өмет һәм теләкләр көнедер. Без барыбыз да бу көнне хатын-кызларга игътибар итеп, аларның тырышлыгы һәм хөрмәтенә тиешле бәя бирергә тырышырга тиеш.

Шулай итеп, 8 Март - хатын-кызларның көче, тырышлыгы һәм ихтыяҗлары турында кабат искәртеп, аларны хөрмәтләү, ярату һәм яклау өчен бер мөмкинлек.

**10 нчы сыйныф укучысы Багавиев Әдел**




## Әниемә

Минем әнием әйбәт,
Бөтен эшкә оста ул,
Өйрәтә мине җайлап.
Мактап күңелне күтәрә
Иң тәмле сүзләр сайлап.

**2 нче сыйныф укучысы Садриева Ралия**



## Яз килә

Әй, яз килә! Яз килә,
Кояш нурларын сибә.
Минем нәни песием дә
Яз килгәнгә сөенә.

Өй кыегында бозлардан
Тама тамчылар тып-тып.
Сыерчыклар җырын суза
Тал чыбыгына басып.

**3 сыйныф укучысы Б.Амира**

## Нәүрүз бәйрәме нинди бәйрәм соң ул?

Без, 2 класс укучылары, ул бәйрәм турында мәктәптә, тәрбия сәгатендә ишетеп белдек. Нәүрүз - күп кенә халыкларның иске календаре буенча Яңа ел бәйрәме икән. “Нәүрүз мөбарәкбад!” Һәр елны 21 мартта язны, яз белән бергә Яңа елны каршылаганнар. 21 март - яз фасылының көн белән төн тигезләшкән көне. Бәйрәм итүнең гореф - гадәтләре, йолалары буыннан - буынга күчеп, безнең заманнарга хәтле килеп җиткән. Бәйрәмдә бер - берeңне татлы ризык белән сыйлау төп кагыйдәләрнең берсе булган. Без дә ул көнне татлы ризыклар белән сыйландык. Табигатьне күзәттек. Кара каргалар килгәнен дә күрдек. Яз темасына рәсемнәр ясадык, җырлар җырладык. Мин язны сагынып көтеп алам.

**2 нче сыйныф укучысы Василов Азат**

## Яхшылык

Яхшылыкта - яктылык
Авыр чакта булышсалар,
Бу – яхшылык,
Тәмле әйбер бүлешсәләр,
Бу – яхшылык.
Әгәр сиңа елмайсалар,
Бу – яхшылык.
Димәк, безнең йөрәкләрдә
Бар яктылык.
Һәрвакытта, бөтен җирдә
Кыл яхшылык.
Дөнья үзе китәр кинәт
Гел яхшырып

**4 нче сыйныф укучысы Аяз Батталов**



## Табигать – зур байлык.

Табигать - ул безнең йортыбыз. Балыклар су-сыз, җәнлекләр урмансыз,ур-маннар агачларсыз була алмаган кебек, кешеләр дә табигатьсез яши алмый. Табигать дигәч, иң беренче булып яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, елгалар, күлләр күз алдына килә. Табигатьсез кеше яши дә алмый, чөнки без табигатькә чыгып ял итәбез, кошлар җырын тыңлыйбыз, хуш исле һәм матур чәчәкләр иснибез. Хәтта беренче ярату да табигатьтән башлана.

Табигать - кешенең яшәү урыны. Ул анда туа, яши, беренче мәхәббәтен таба. Табигать кешене сокландыра, тынычландыра һәм авыр чакта булыша. Табигатьне пычрату ул - бер зур гөнаһ булып тора. Кайбер кешеләр аны чиста тота, әмма аларның арасында гөнаһлы кешеләр дә бар. Табигать ул безнең җиребез. Һәр язучы да, шагыйрь, рәссам, композитор, табигать һәм хайваннар турында язмый калмый, хәтта кечкенә балалар да табигатьне тасвирлый. Әдәбият китапларында да искиткеч матур пейзажлар бар.

Туган якның табигате һәркемнең күңелендә кала. Һәр кешегә дә үз туган җире бик кадерле. Шуңа күрә язучылар үз әкиятләренә тормышның бер өлешен кертәләр.

Табигать турында яза башласаң, аның кошларын, хайваннарын нәкъ кешеләр турында язган кебек матурлар сурәтләп язалар. Табигать дөньяда бик мөһим урын алып тора.

**6 нчы сыйныф укучысы Мирхазианова Алия**




## Бөек Җиңүдә гаиләбез өлеше

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу турында мәктәптә укытучыбыз белән тәрбия дәресләрендә сөйләшәбез. Сугыш ул авылдагы һәр кешегә кагылган. Кемнеңдер бабайсы, әтисе, абыйсы, апасы, үзе, туганы сугышта катнашкан. Мин дә бабайларымның сугышта катнашканын беләм. Өйдә гаиләбез белән сугышта катнашкан бабаем Сабирҗанов Мөхәммәт Сабирҗан улы турында хатирәләребезне яңарттык. Аның сугыш истәлекләрен улы Рәдиф бабай сөйләде. Рәдиф бабай – әтиемнең әтисе.

Мөхәммәт бабайга 1941 елның декабрендә 18 яшь тула. 1942 елның гыйнвар аенда аны сугышка алалар һәм Ерак Көнчыгышка җибәрәләр. Дивизияләре Хабаровск шәһәре янында тора. Ике ай хәрби өйрәнүләр үтәләр. Алар алдына илебез чикләрен японнардан саклау бурычы куела. Японнар да илебез чикләренә һөҗүм ясап торганнар. 1942 елның җәендә Сталинград янындагы фронтларда немец гаскәрләренең һөҗүме көчәя. Бабайларны Ерак Көнчыгыштан, 577 нче укчы полк составында, Сталинградны сакларга күчерәләр. Алар немецларның бик күп һөҗүмнәренә каршы торалар. Дошманга алга барырга ирек бирмиләр. “Немец солдатлары яхшы коралланган булсалар да, без бар булган коралларыбыз һәм җаныбыз – тәнебез белән каршы тордык. Сталинградны дошман кулына бирмәдек.” – дип сөйләгән ул. Немец гаскәрләре Сталинградны ала алмый, җиңелүгә дучар була. Сталинград янындагы сугышларда бабайның кулы яралана, бармаклары өзелә. Башта Казахстандагы госпитальдә була. Аннан Урал төбәге Азин шәһәрендәге госпитальдә дәвалана. 1943 елның маенда, сәламәтлеге буенча сугышка ярамагач, туган авылына кайтарыла.

Сугыш вакытында тылдагы тормыш та бик авыр була. Барлык эш хатын – кызлар һәм балалар җилкәсендә. Мөхәммәт бабайны икенче көнне үк колхозда бригадир итеп куялар. Колхозларны берләштергәч, агротехник булып эшли. Кабат бригадир вазыйфасына куела. Озак еллар ревкомиссия рәисе булып эшли.

1943 елда гаилә кора. Зәкия әби белән җиде бала, дүрт егет һәм өч кыз тәрбияләп үстерәләр.

Бөек Ватан сугышында катнашкан өчен бабай I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән, “Германияне җиңгән өчен” медале, юбилей медальләре белән бүләкләнә.

Илебезне дошманнан азат итүдә катнашкан Мөхәммәт бабаем белән без, аның оныклары горурланабыз. Сугышлар булмасын, без тыныч тормышта яшәргә телибез.

**1 нче сыйныф укучысы Сабирзянов Әскәр**



## Ватан сакчысы - кем ул, нинди ул?

14 нче март көнне безнең мәктәбебезгә кунаклар – тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары һәм директор киңәшчеләре килде. Алар безнең сыйныфка тәрбия сәгате карарга керделәр.

Без ул көнне Ватанны саклаучылар турында сөйләштек. Ватаныбызның үзебезнең нигездән, гаиләбездән, өй түрендә үскән чәчкәләрдән башлануын ачыкладык. Төрле елларда Туган илебезне саклаучы дәү бабаларыбыз, әбиләребез(сугыш чоры балалары), әти-абыйларыбыз, бүгенге махсус хәрби операциядә катнашучы авылдашларыбыз, алар кылган батырлыклар турында сөйләштек. Төркемнәрдә погоннар җыйдык, “Сүзләр болыты” төзедек. Без дә үз чиратыбызда киләчәктә кыю Ватан сакчылары булырбыз, Туган илебез ышанычлы кулларга калыр дип уйлыйм.

**4 нче сыйныф укучысы Шигапов Ранил**

## Халык хәтере

Халкыбызның фашизмны җиңүенә быел 80 ел тула.1945 нче елның дулкынландыргыч 9 нчы мае ватаныбызның гына түгел, ә бөтен кешелек тарихына кереп калды. Ил чикләрен 1941 нче елның 22нче июнендә герман илбасарлары басып керә. Зур сынаулар килә илгә , бик зур югалтулар була. Халкыбыз 872 көн блокада да яшәгән. Домшанны илебездән куып чыгарып, тар мар итеlә. Без зур тырышлык һәм зур югалтулар бәрабәренә җиңү алып килгән сугыш һәм хезмәт батырлары белән горурланабыз. Еллар ничек кенә үзгәрмәсен, әлеге шатлыклы һәм шул ук вакытта моңсу бәйрәм илебездә иң мөһим, иң изге даталарның берсе булып калыр.

Бөек Ватан сугышы елларын, анда булган вакыйгаларны без китаплардан укып, кинолардан карап кына беләбез. Күпме ир егетләр, апалар-абыйлар, яшүсмерләр сугыш кырларында мәңгелеккә ятып калган. Меңәрләгән шәһәрләр җимерелә, авыллар юкка чыга. Әмма тылда калганнар да зур батырлыклар күрсәткәннәр. Хатын-кызлар сугыш вакытында күп авырлыклар кургәннәр. Ләкин ач-ялангач тормыш, авыр хезмәт аларны куркытмаган. Завод-фабрикаларда, басу-кырларда тырышып эшләгәннәр.

Сугыш башланганда минем карт әбием-Мәрьям Шаһимәрдән кызына 32 яшь булган. Ул да Җиңү көнен якынайту өчен барысында эшләгән. Ике берсеннән-берсе кечкенә баласын өйдә калдырып, җәй көне урак урган, кыш көне урманда агач кискән, аннан бушаган арада фронтка җибәрергә җылы оекбашлар,бияләйләр бәйләгән. Аның тормыш иптәше-карт бабам Мәулит Сибгатулла улы да 1941 нче елда сугышка алына. Сугыш кырында күп батырлыклар кыла, ләкин ул әсирлеккә төшә. Бабаем төшенкелеккә бирелмәгән, башка әсирләргә ярдәм иткән, чит телләр белү сәбәпле аларга ризык та табышкан. Ул күп газаплар күргәннән соң, әсирлектән кача алган. Кабат фашистларга каршы сугышуын дәвам итә ул. Бик күп орден -медальләр белән бүләкләнә. Җиңү яулап,туган авылы Балыклыга кайта. Кызганычка каршы, бабаемның ике энесе Галимхан белән Галимҗан абыйлар, әбиемнең абыйсы Әхмәтвәли абый сугыш кырында мәңгелеккә ятып калалар. Сугыштан соң, хуҗалыкны торгызуга, яна тормыш коруга тотыналар. Иген үстерәләр, балалар тәрбиялиләр.

Мин халкыбызның кылган батырлыкларын һәрвакыт хөрмәт итәм һәм сокланам. Ул елларда әби-бабаларыбыз кылган батырлыкларны онытмыйча, бездән соң килгән буынгада да житкерү-безнең бурычыбыз булып тора. Без мәктәптә төрле чараларда катнашабыз. Күргәзмәләр оештырабыз, проектлар яклыйбыз.

**5 нче сыйныф укучысы Һадиева Иделия**




## Акциядә катнаштык

20 мартта Бөтендөнья Жир көне билгеләп үтелә. 1971 елда БМО Генераль Секретаре керткән бу дата ел саен язгы көн-төн тигезлеге алдыннан үткәрелә. Күптөрле чаралар һәм акцияләр – конференцияләр, күргәзмәләр үткәрелә. Төп максат – дөнья халкы игътибарын Жир планетасы һәм әйләнә-тирәлек проблемаларына юнәлтү. Без бу уңайдан тәрбия сәгате уздырдык. Экология, табигатьне саклау,заказниклар темасын яктыртып рәсемнәр ясадык. Акция кысаларында макулатура җыйнап тапшырдык. Макулатура җыю – урманнарның, туган җиребезнең, ахыр чиктә планетабызның табигый матурлыгын саклау гына түгел. Кәгазь калдыклары җыю ул әле сакчыллык та, хезмәт тәрбиясе дә. Бу эшкә һәркем үз өлешен кертә ала. Без дә бердәм булып бу акциядә актив катнаштык. Макулатураны уку елы дәвамында берничә тапкыр җыябыз. Бу чара инде безнең традициягә әйләнде. Барлык укучылар да актив катнаша. Һәр акциядән соң нәтиҗә ясап, җиңүче сыйныфларны, актив укучылар билгеләнә. Җиребез тыныч булсын, матур табигате, чиста һавасы белән кадерле ул.

**5 нче сыйныф укучысы Низамова Дәринә**

## Туган җирем – таулар иле.



Минем исемем – Гулнахор, ә энем- Самад.
Безнең Туган җиребез - Таджикстан. Башкаласы – Дүшәмбе. Башкала бик матур, анда парклар, музейлар бар.
Безнең туган авылнының исеме - Дархон. Авылыбыз янында биек таулар бар. Таудан чишмә сулары агып төшә.Тауларга экскурсиягә барабыз.
Бик матур агачлар, файдалы үләннәр үсә. Безнең авылда бакчаларда җиләк –җимеш агачлары күп. Алмалар бик сусыл, тәмле.
Авылыбызда изге җир бар.Анда бер агач төбеннән су чыга, ул бик шифалы су. 1 нче майда бөтен халык шунда бара, догалар кылалар.
Туган якның кадере читкә киткәч беленә. Мин туган ягымны яратам, сагынам. Һәр кеше дә туган җиренең кадерен белергә һәм сакларга тиеш. Безнең абыебыз Марат икенче елын Таджикстанның хәрби армиясендә хезмәттә. Без аның белән горурланабыз.

**8 нче сыйныф укучысы Юлдошзода Гулнахор**